КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 декабрь г.Казань № 1111

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче; 2016 ел, 27 июль, 517 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 805 нче; 2018 ел, 4 июль, 552 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1052 нче; 2018 ел, 18 декабрь, 1160 нчы; 2019 ел, 21 март, 197 нче; 2019 ел, 9 декабрь, 1130 нчы; 2020 ел, 20 март, 211 нче; 2020 ел, 10 апрель, 269 нчы; 2020 ел, 17 апрель, 302 нче; 2021 ел, 23 август, 770 нче; 2021 ел, 3 ноябрь, 1044 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 55 нче; 2022 ел, 21 ноябрь, 1250 нче; 2023 ел, 14 март, 247 нче; 2023 ел, 3 июнь, 686 нчы; 2023 ел, 28 ноябрь, 1527 нче; 2024 ел, 21 август, 678 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр

министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Янгынга каршы дәүләт хезмәте көчләре белән янгыннарны (урман янгыннарыннан, ябык административ-территориаль берәмлекләрдә, федераль территориядә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган илнең милли иминлеге өчен критик мөһим, башка аеруча мөһим янгын чыгу куркынычына ия объектлар, Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектлары исемлегенә керә торган объектларда, ябык административ-территориаль берәмлекләрдә, федераль территорияләрдә, шулай ук кешеләрне күпләп җыеп, федераль дәрәҗәдәге чараларны үткәргәндә янгыннардан тыш) сүндерүне оештыру һәм ландшафт (табигать) янгыннарын (урман фонды җирләрендә, оборона һәм иминлек җирләрендә, махсус сакланыла торган табигать территорияләре җирләрендә урман янгыннарыннан һәм башка ландшафт (табигать) янгыннарыннан тыш) сүндерү планнарын эшләү, шулай ук мондый янгыннарны Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге законнар нигезендә эшли торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы көчләре һәм чаралары белән сүндерүне оештыру (алга таба – янгыннарны сүндерүне оештыру);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин